**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«14» март 2019 ел** **№ 141**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә ачык (гавами) тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

Халыкның уңай тормыш шартларына хокукларын тәэмин итү, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары буенча Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә яшәүчеләр катнашында фикер алышулар максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. «Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә ачык тыңлаулар турында нигезләмә хакында» 2006 елның 23 декабрендәге 51 номерлы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **А.С.Быля**